ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАКТАЛАЧЫК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423751, Такталачык авылы,
Г.Авзал урамы, 48нче йорт.
тел.3-44-57

ТАКТАЛАЧУКСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423751, с.Такталачук,
Ул.Г.Авзал,
дом 48, тел. 3-44-57

# КАРАР

«17» январь 2020 ел №3

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлегендә балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиянең 2020 елга эш планын раслау турында

«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 14.10.2011 № 71-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Такталачык авыл җирлеге Уставы нигезендә, балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны кисәтү һәм профилактикалау, гаиләләр белән профилактик эш алып бару максатыннан КАРАР БИРӘ:

1. Такталачык авыл җирлеге башкарма комитеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре буенча иҗтимагый комиссиянең эш планын (1 нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми pravo.tatar.ru сайтында, Такталачык авыл җирлеге http://aktanysh.tatar.ru/rus/aktanysh/poselenia сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Такталачык авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе М.Т.Мансуров

Такталачык авыл җирлеге
Башкарма комитет
җитәкчесенең
17.01.2020ел №3 карарына
кушымта

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең

2020нче елга эш планы

| № п/п | Мероприятие | Үтәү вакыты | җаваплы | Кем белән берлектә үткәрелә |
|---|---|---|---|---|

Оештыру-методик эш

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышы (Татарстан Республикасы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районындагы беркетмәләре һәм күрсәтмәләре буенча балигъ булмаган балаларга һәм аларның ата-аналарына карата материалларны карау, белем бирү учреждениеләре тәкъдимнәре һәм үтенечнамәләре, гражданнарның шикаятьләре, торак шартларын тикшерү актлары һ. б.) | Кварталга 1 тапкыр | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 2. | Такталачык авыл җирлеге авылларында КБН һәм ЗП күчмә утырышларын үткәрү | Квартал саен | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 3. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рейдлары | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4. | Балигъ булмаганнар арасында эчкечелекне кисәтү максатыннан яшүсмерләр концентрациясе урыннары (дискотекалар, урамнар) буенча рейдлар | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 5. | Сәүдә нокталары буенча рейдлар | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 6. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы КДН һәм ЗП утырышларында чыгарылган штрафлардан качып йөрүче гражданнар буенча рейдлар | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 7. | Имин булмаган гаиләләрне ачыклау һәм аларны КДН, ЗП һәм ПДНда исәпкә кую | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 8. | Балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча яшүсмерләр һәм аларның ата-аналарын кабул итү | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 9. | Гаилә көненә, Балаларны яклау көненә, Яңа елга багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |

балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышында карау өчен чыгарылган мәсәләләр

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларның һәм җинаятьләрнең торышы турында | Квартал саен | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 2. | Дәресләргә йөрмәгән балалар турында һәм мондый очракларга | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | юл куймау буенча җирлек мәгариф учреждениеләре тарафыннан күрелгән чаралар һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия составы турында мәгълүмат | | | |
| 3. | Яшәү урыны буенча Балигъ булмаганнарның ялын оештыру турында | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 4. | Күп балалы һәм имин булмаган гаиләләр белән эшләү | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 5. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссия эшенә йомгак ясау | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |